Республика Татарстан

САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 августа 2025 года № 266

Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башкарма комитетының 03.06.2014 №54 карары белән расланган Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» һәм ««Элемтә турында» Федераль законның 6 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 23.07.2025 ел, №251-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 03.06.2014 ел, №54 карары белән расланган Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4. пунктының 2.4.1 подпунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә «, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары»;

1.2. 2.4. пунктының 2.4.2 подпунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә «, элемтә линияләренә һәм элемтә корылмаларына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге рәсми сайтында https://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча урнаштырырга.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р. Г. Гыйлманов